РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» марта 2020 ел г. Альметьевск № 323

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының «Әлмәт
муниципаль районы гомуми
белем бирү учреждениеләрендә
укучыларны тукландыруны оештыру
турында» 2015 елның 31 декабрендәге
1581 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

«2020 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 28 августындагы 724 номерлы карары нигезендә һәм укучыларны кайнар туклану белән вакытында тәэмин итү максатларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2015 елның 31 декабрендәге 1581 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 30 октябрендәге 1756, 2018 елның 30 мартындагы 425, 2018 елның 25 декабрендәге 2254, 2019 елның 10 июнендәге 1122, 2019 елның 3 сентябрендәге 1633 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 1973 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «2020 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 28 августындагы 724 номерлы карары нигезендә уку елы дәвамында бер укучыга көнгә 7 сум 70 тиен күләмендә акчалата түләүләр бәясе исәпләнә. Балансль туклану нормативына туры китереп, аерма укучыларның ата-аналары исәбеннән түләнә.

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

Зак. № 305-2000

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов